МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.08.2020 г.Казань № 561

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 27 августында 6849 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 18 ноябрендәге 1043 номерлы «2020 елда вакытлыча эшкә урнаштыру чорына балигъ булмаган һәм эшсез гражданнарга матди булышлык күрсәтү күләмнәре турында» боерыгының 1 пунктына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 18 ноябрендәге 1043 номерлы «2020 елда вакытлыча эшкә урнаштыру чорына балигъ булмаган һәм эшсез гражданнарга матди булышлык күрсәтү күләмнәре турында» боерыгының 1 пунктына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 29 маендагы 370 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

икенче, өченче һәм дүртенче абзацларда «эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменнән 1,5 тапкыр» сүзләрен «2250 сум» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче һәм алтынчы абзацларда «эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменнән 3 тапкыр» сүзләрен «4500 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.А. Зарипова